# КАРАР

**22 ноябрь, 2024 ел** **№1**

**Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлеге Ташлы Елга авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 22 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«Сез 2025 елда Кукмара муниципаль районының Кәркәүч авыл җирлеге Ташлы Елга авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге 4 яисә аннан да күбрәк баласы булган күп балалы гаиләләрдән; 85 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 700 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (вак таш белән капланган юлларны төзү, ремонтлау һәм төзекләндерү, траншеяларны экскаватор белән эшләү, проект-смета документациясен эшләү һәм технадзорны гамәлгә ашыру, юлларны төзекләндерү, карап тоту һәм төзекләндерүнең башка төрләре);
- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урамнарны яктыртуны карап тоту, комплектлаучы әйберләр сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документациясе һәм технадзорны гамәлгә ашыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка төр эшләр);
- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су белән тәэмин итү челтәрләрен, су саклау зоналарын һәм су җыю башняларын карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, янгын сүндерү гидрант һәм тирәнлек насосы, проект-смета документациясе, технадзорны гамәлгә ашыру, су белән тәэмин итүне, су саклау зоналарын һәм су җыю башняларын карап тоту буенча башка төр эшләр;);
- торак пункт территориясен төзекләндерү (Ташлы Елга авылы территориясен төзекләндерү, юлларны кардан чистарту, юлларны җәйге карап тоту, җәйге вакытта территорияне чабу, табигый яткан грунтларда куаклык һәм вак урманнарны кисү проект-смета документациясен эшләү һәм технадзорны гамәлгә ашыру, башка төр эшләр);

(спорт мәйданчыгын ремонтлау, проект-смета документациясе, технадзорны гамәлгә ашыру, башка төр эшләр);

(агачларны йоклатты һәм чүп-чарны чыгару, проект-смета документлары, технадзорны гамәлгә ашыру, башка төр эшләр)

-торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр күперләрен һәм юл

үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау (Татарстан урамындагы күпер кырыйларында саклагыч койма сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документациясе, технадзорны гамәлгә ашыру, башка төр эшләр);

- һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) булмаган) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (һәйкәлне сатып алу һәм яктырту, проект-смета документациясе, технадзорны гамәлгә ашыру, башка төр эшләр);

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 220 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 113 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 113 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлегенең Ташлы Елга авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Сез 2025 елда Кукмара муниципаль районының Кәркәүч авыл җирлеге Ташлы Елга авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге 4 яисә аннан да күбрәк баласы булган күп балалы гаиләләрдән; 85 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 700 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (вак таш белән капланган юлларны төзү, ремонтлау һәм төзекләндерү, траншеяларны экскаватор белән эшләү, проект-смета документациясен эшләү һәм технадзорны гамәлгә ашыру, юлларны төзекләндерү, карап тоту һәм төзекләндерүнең башка төрләре);

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урамнарны яктыртуны карап тоту, комплектлаучы әйберләр сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документациясе һәм технадзорны гамәлгә ашыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка төр эшләр);

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су белән тәэмин итү челтәрләрен, су саклау зоналарын һәм су җыю башняларын карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, янгын сүндерү гидрант һәм тирәнлек насосы, проект-смета документациясе, технадзорны гамәлгә ашыру, су белән тәэмин итүне, су саклау зоналарын һәм су җыю башняларын карап тоту буенча башка төр эшләр;);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Ташлы Елга авылы территориясен төзекләндерү, юлларны кардан чистарту, юлларны җәйге карап тоту, җәйге вакытта

территорияне чабу, табигый яткан грунтларда куаклык һәм вак урманнарны кисү проект-смета документациясен эшләү һәм технадзорны гамәлгә ашыру, башка төр эшләр);
(спорт мәйданчыгын ремонтлау, проект-смета документациясе, технадзорны гамәлгә ашыру, башка төр эшләр);
(агачларны йоклатты һәм чүп-чарны чыгару, проект-смета документлары, технадзорны гамәлгә ашыру, башка төр эшләр)
-торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау (Татарстан урамындагы күпер кырыйларында саклагыч койма сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документациясе, технадзорны гамәлгә ашыру, башка төр эшләр);
- һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) булмаган) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (һәйкәлне сатып алу һәм яктырту, проект-смета документациясе, технадзорны гамәлгә ашыру, башка төр эшләр);

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип исәпләргә.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәсен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ruадресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Кәркәүч авыл
җирлеге башлыгы

М.Ф.Зайнутдинов